## Татарның илли өлгесе

*(Тирән фикерле, илаһи һәм милли рухлы, Алла канунnарының дөньяви кануннардан өстенлеген, иман белән фәнни гыйлемнең берлеген танучы, вәсвәси сафсатадан азат булган татарлар өчен).*

### Кыскача мәгълумат

Татар халкы 460 йылдан артык инде Алла биргән ирекен югалту сәбәпле күпчелек халыклар шикелле “цивилизацион” коллыкта йәши. Шул дәвердә ул күп мәртәбә ирекка омтылыш ясап караса да, зур югалтулар белән артка чигенә. Соңгы 1986 йыл апрель инкыйлабы да аны бу халәттән чыгармады. Әлеге чорда барлыкка килгән милли күтәрелеш тә җиңелүгә дучар ителде. Халык үз язмышына буйсынып әкәм-төкәм шикелле үз кабыгына кереп бикләнде. Рухи, милли-мәдәни үсеш тукталды, матди-мәтдәви кыйммәтләр белән исереп, татар яңадан мәрткә китте.

Ә иң аянычы - һәр җиңелүдән соң ул үзенең илаһи куәтен җуя бара. Чөнки һәр хәлиткеч бәрелештә милләтнең иң яхшы уллары кырыла, кызлары мәсхәрә ителә, мыскаллап җыйылган каймагы (гумусы) юыла. Аның каравы, милли таркалыш нәтиҗәседә барлыкка килгән зарарлы матдәләре, иң яман сыйфатлары туплана. Болар коллыкка каршы торган тумыштан килгән иммун системасын җимерә.

Ничек болай булды әле, зур мәмләкәтләр төзегән, цивилизацийәләр тудырган, куәтле дәүләтләр корган горур һәм буйсынмас түрек кәвеменең варислары мескен коллар дәрәҗәсенә төштеләр? Кайчан һәм ничек кулга ийәләштереп булмаган бүреләр ялагай этләргә әйләнделәр? Ни өчен ирекле кешеләрнең табигый сыфатлары булган намуслылык, турылык, миһербанлык хашәрәт коллар мәкерлегенә, хаинлегенә һәм куркаклыгына әйләнде? Ни өчен һәр ирекка омтылыш тагы да тирәнрәк коллыкка төшү белән тәмамлана? Рухның бу кадәр тирән түбәнлеккә төшүенең төп сәбәбе нидә? Татар халкының кайчан да булса ирекка чыгуына өмет бармы? Әллә инде ул чыннан да мәңгелек йокыга талган? Алла биргән илаһи сыйфатларын җуйып мәңгегә бәйдәге этләрнең язмышына дучар ителгән?

Әгәр без бу сорауларга өздереп җавап бирә алмасак, һәр ирек даулавыбыз коллыкны тирәнәйтәчәк, һәр җиңелүебез каршы көчләрнең куәтен арттырчак.

Әлегә исә без үзебезнең коллык халәтебезне Мәскәүдән, урыстан, йә йәһүдтән күрәбез. Әмма безнең һәрбер җиңелүебез Мәскәүнең баскынчылык сәйәсәтеннән бигрәк, татар җәмгыйәтенең тирән таркалышы, бик күп катламнарга бүленеше, кыйбласын, йәшәү йегәрлеген югалтуы, илаһи куәте кимүе, гасырлар буйы тәрбийәләп үстергән рухи, милли-мәдәни, матди-җәмгыйәви тамырларыннан айырылып, рухына ят үсентеләргә тоташуы белән билгеләнгән. Шул сәбәпләр аркасында, зәррә дәрәҗәсенә төшкән милли таркалыш, гомумән алганда, татар халкының һәм татар милләтенең барлыгы мәсьәләсен бөтен кискенлеге белән куя.

Кызганыч ки, минем күпчелек милләттәшләрем бу аяныч хәлнең сәбәбен бары тик татарның мөстәкыйль дәүләте булмаудан күрәләр һәм дәүләт булгач та милләт тиз терелачәк дип уйлыйлар. Һәм һич тә, милләт дәүләт беткәч түгел, кыйбласын югалткач бетә дигән фикер белән килешмиләр. Мин исә дәүләт кору өчен, беренче чиратта, милләтне торгызырга һәм моның өчен аның кыйбласын турыларга кирәк дип саныйм. Шунда инде безнең бар каршылык. **Бөтен хикмәт шунда ки, татар**

**кыйбла итеп илаһийәт дөньясынмы, әллә көфер дөньясынмы сайлый. Бүген исә аның бөтен вөҗүде садум гонаһына баткан көфер дөньясына йүнәлгән.**

Татар милләт булып көфер дөньясына каршы торырлык илаһи гакыйдәгә таянып кына ойыша алачак. Әгәр ул моны эшли алмаса, маргинал халәткә төшеп башка халыкларның икенчел күчермәсенә әйләнап, алар арасында эреп-таркалып, йотылып бетәчәк. Моны расларга күп кирәкми. Бу процесслар күз алдында бара.

Шул уңайдан бер фикер китерәм. Без, әйткәнемчә, дәүләт бәйсезлегебезне югалтуны Мәскәүгә, урыска, "явыз иванга" сылтыйбыз. Тик нигәдер "татар өлешен" күрмәскә тырышабыз. Шаһгалилар, Камай морзалар турында түгел, үзара тәхет, мал бүлүче ханнар, морзалар, бийләр турында әйтәм. Ә бит Бөйек Болгарны, дәһшәтле Алтын Урданы урыслар, йәһүдләр түгел, төрки-татарлар җимергән. Әнә Ибак дигән "морза" Алтын Урданың соңгы ханы Әхмәтне үтереп шәхси үзе Мәскәү патшасы Василийны шатландырган. Аксак Тимерләр, Миңле Гәрәйләр, Тохтамышлар, Идегәйләр турында әйтмим дә инде. Ә без мәйданда 22 йәшлек "явыз ванькага" озын сакал элеп кәгазь рәсемен яндырабыз. Бар явызлыкны аңа сылтыйбыз. Ә Казан ханнары тәүфик ийәсе, беркемгә дә юктыр тийәсе. Әнә бит шагыйребез Мохаммәдяр да "кяфер белән әле йәшәп була, ә залим белән йәшәп булмый" ди. Мәскәү белән Казанны ул Кяфер белән Золым исемле ике игезәк итеп күрә.

Юк, мин Мәскәүне дә, урысны да акларга җыйынмыйм, һәркемнең Алла каршына барасы бар, әмма күңелгә ни кадәр авыр булмасын, татарга диагнозны дөрес куярга кирәк. Шунда гына дөрес дәва таба алачакбыз. Югыйсә өч фиркәгә бүленгән ике татарга иртәгә дәүләт бирсәң бройлер чебиләр кебек бер беребезне ашап бетерәчәкбез. Чөнки көфер китсә, золым кала. Аннан арыну көферне куудан күпкә кыйынрак. Әнә бит күренекле инглиз социологы Арнолд Тойнб юкка гына "цивилизацийәләр … үтерү корбаны түгел, ә мордарлык корбаны дип әйтмәгәндер".

Туксанынчы йылларда берничә төрки халык дәүләтле булды, әмма ирекле булды дип әйтеп булмый, чөнки дәүләт башында шул ук залимнәр калды. Ә гади халык һаман да аны садум гөнаһына баткан көфер дөньясыннан көтә. Аның "халыкара кануннарына" ышанып, хәтта канга батып, Алладан ваз кичеп иманыннан яза. Ә бит Мохаммәд г.һ.с. бер дә юктан мең ярым йыл йәшәүче дөньякүләм ислам цивилизацийәсен тудыра. Гарәпләрне бөтен дөньяга таныта. Ә безнең патшалар төзегәнен дә туздыра. Төрки халыкларны мең йыллык коллыкка төшерә.

Әнә бит, Алла да бозык халыкларны башка халыклар белән алмаштырырмын дигән. Бәлки бу татарга да кагыладыр. Аны Алла юлыннан тайпылган өчен урыс халкы белән алмаштыргандыр. Явыз иваннарны моңа сәбәпче генә иткәндер.

Татарның маргинал катламы бүген дә милләт язмышына йә битараф, йә аның кирәклеген бөтенләй инкарь итә. Кайбер имамнарыбыз да диндә милләт юк дип баралар. Ә бит Алла үзе Мин сезне тәкъвалылыкта сынашу һәм алдымда исәп тоту өчен кавем-кавем яраттым, ди. Шулай булгач милләттән ваз кичү, Алланың үзеннән ваз кичү түгелме? Моның өчен андый бәндәне Алла бөтенләй имансыз да калдыруы ихтимал. Барлык сәбәп-нәтиҗәләре белән. Әнә бит, мәшһүр галимебез Шиһабетдин Мәрҗани дә ни ди: "Татар булуны бер кимчелек санап, ул исемнән чирканып, без татар түгел, "мөселман" дип, тавыш-җәнҗал чыгаручылар бар. Нинди кызганыч хәл. Татар булмасаң, гарәп, таҗик, нугай түгел, кытай, урыс, француз да түгел, инде кем булырсың?". Милләтеннән ваз кичкән татар иртәме-соңмы диненнән дә яза.

Шулай да Алла безне динсез калдырмаган. Тәнресеннән баш тартса да, динен

ислам нуры белән яңарткан. Шуңа күрә җәһли коллык шартларында югалткан илаһи гакыйдәсен (идейәсен) һәм милли өлгесен торгызган очракта ул туып килүче рухи цивилизацийәнең әйдәүче бер кавеме була алачак. Әлбәттә моның өчен иң беренче үзенең сыйфат күрсәткечләрен (идентификаторларын) барларга, аларны торгызырга һәм илаһи силсиласын (рухи куәтен) кайтарырга тийеш булачак.

Татарның илаһи гакыйдәсен кыскача болай формалаштырырга була: **татарлар бер Аллага (Тәңрегә) буйсынган мөэмин (камил) милләт буларак формалаша һәм илаһи кыймматләр системасына күчкән башка милләтләр белән бергә әйдәүче милләт сыйфатында төрки, славян, угор халыкларының уртак ватаны булган Татар иле-Русийәне туып килүче дөньякүләм рухи цивилизацийәнең әйдәүчесе итеп үзгәртү өчен тырыша.** Шуннан түбән дәрәҗәдәге гакыйдә бу халыкларны рухи таркалыш кичергән җәһлийәт дөньясының казанында эретеп, икыйразга илтә һәм тарихи йәшәү перспективасыннан мәңгегә мәхрүм итә. Бу мәсләк үзен генә дәүләт төзүче дип санаган урыс халкына да кагыла. Чөнки аның да милләт булып ойышу өчен илаһи гакыйдәсе дә, милли өлгесе дә юк. Ә без тәкъдим итә торган милли өлге башка милләтләргә дә үрнәк була ала. Мин монда мөселман татарларының милли өлгесен китерәм, башкаларның моңа үз ихтыяры.

Әлеге илаһи гакыйдәдән килеп чыккан татарның сыйфат күрсәткечләре (индификаторлары) аның милли өлгесен хасил итә һәм рухи куәте рәвешендә цивилизацион потенциалын билгели. Кыскача аларның эчтәлеге мондый:

1. Милләт булып йәшәү җирлеге – Алтын Урда, Идел-Урал, Бөйек Болгар чикләре. Шуңа күрә без аны таркатырга җыйынмыйбыз. Бары тик аны илаһийәт юлына чыккан җирле, тамырдаш милләтләрнең уртак ватаны итәргә тырышабыз. Беренче булып Русийәне мәмләкәт итеп җыючы һәм дәүләт төзүче халык ул татар халкы. Моны Русийә президенты администрацийәсе каршында ойыштырылган Русийә стратегик эзләнүләр институтының кайбер белгечләре да таный башлады. Безнең дәүләтчеләребез исә аны ясалма Татарстан чикләрендә генә күрә һәм бөтен Русийә күләмендә Татар илен торгызырга тыршуны Мәскәүгә буйсыну итеп карый.

2. Алла биргән «кендек җире» – Татарстан, Бөтендөнья милли идарә үзәге - Казан. Татарстанда татар дәүләтен төзеп, Русийәдә Татар илен корып йәши.

3. Дине – эчтәлеге белән илаһи, формасы белән милли татар исламы (мәҗүсилектән арынган, түрек дөньясына иңдерелгән илаһи тәңречелек).

4. Теле – иске татар теленнән үсеп чыккан, аның лингвистик нормаларына (кануннарына) нигезләнеп хәзерге заман гарәп, фарсы, түрек, славян, латин терминологийәсе белән байытылган бүгенге илаһи төрки-татар теле.

5. Имласы – кәмпитер конверторы йәрдәмендә кириллицага, латинга, руни язуга җиңел күчерелә торган бүгенге заман татар-гарәп имласы.

6. Мәгариф системасы – милли. Теле – татар-мөселман теле. Эчтәлеге – рухи дөньяви. Фәнни гакыйдәсе – яратылыш тәгълимәте, креацион тәгълимәт.

7. Милли исемнәр – кануный яктан бозылмаган төрки-татар исемнәре.

8. Милли ономастика и топонимика – татарның “кендек җире” һәм милли ватаны белән бәйле, аның йәшәү мохитен тәэмин итүче, кануный яктан төзек һәм этник асылы бозылмаган (калькалаштырылмаган) төрки-татар терминары.

9. Җәмгыйәви тормышы: милли-илаһи хокук, икътисад системалары, исламның социаль доктринасы, дини һәм милли гореф-гадәт, йолалар нигезендә.

10. Милли идарә системасы - халык идарәсе - астан өскә йүнәлгән вертикаль буйынча: шәхес, гаилә, мәхәллә, җәмгыйәт, җыйын, мәҗлес.

Әлеге өлге теләсә нинди мәдәни-социаль үзгәрешләр, рефоралар, яңартуларга карата һәрвакыт инвариант (үзгәрешсез) кала. Мисалга кайбер математик матрицаларны, гарәп теленең тамыр системасын китерергә була.

Бу өлге ни дәрәҗәдә үзен татар дип санаган халык тарафыннан үтәлә соң?

Туры әйткәндә, ул бүгенге көндә бөтенләй дийәрлек үтәлми. Бездә һәр татар үзенә акрым бер милләт итеп хис итә. Үзеннән башка берәүне дә танымый. Шуңа күрә нийәтебез риялыкка, сүзебез вәсвәсәгә, гамәлебез күсәк-күкрәккә кайтып кала. Мондый шартларда ничек милләт төзисең дә, аны саклау өчен дәүләт корасың?

Мин әлеге өлгене эшләүне туксанынчы еллар башында ук башлаган идем. Фәлсәфи яктан да, нәзәри яктан да, гамәли яктан да. Әмма аңа рәмси хакимият тә, рәсми динията тә, рәсми милли структуралар да, милли дәүләтчеләр дә битараф калды. Рәсми структуралар Рәсәй кануннары белән, милләтчеләр дәүләт көтеп яшәде. Төп сәбәп монда наданлык, күңел тарлыгы, риялык, комсызлк булды.

Соңгы вакытта мин бу эшләрне интернет сәхифәләренә урнаштыра башладым. Әмма аларда берникадәр теләктәшлек тапсам да, эш гамәлгә җиткәч, сүз боткасына әйләндерү башлады. Чөнки берәүнең конкрет тәкъдимнәре булмады.

Шуңа күрә, бу хезмәтләрне сайтларга урнаштыруны дәвам иткән хәлдә, өлгегә кагылган тәкъдимнәрне, эшләнмәләрне минем электрон почтама җибәрүне үтенәм. Алар, өлгегә кагылган таләпләргә җавап биргән очракта, минем шәхси сайтыма урнаштырылачак һәм кануный рәвешкә китерелеп Татар канунына кертеләчәк. Әлбәттә авторларның исеме күрсәтелеп. Сафсата, вәсвәсә, сүз боткасы белән генә милли проблеманы чишеп булмый. Безгә үз Талмудыбыз кирәк. Моны безгә татардан башка беркем дә эшләмәячәк. Дәүләт булса да, булмаса да.

Әлбәттә, язмалар, эшләнмәләр саф татар телендә, татар кирилында булса яхшырак булыр иде. Тик нигәдер безнең милләтпәрвәрләребез дә һаман да урыс телендә, ватык татар телендә, урыс кирилында яза. Ә бит кәмпитердә моңа бөтен мөмкинлекләр бар. Минем кәмпитернең Тел панелендә алты имла саклана: татар, урыс, инглиз, төрек, гарәп фасы. Латинда язылган хезмәтләр кабул ителми.

Минем электрон адрес: ildus.amirhan@yandex.ru
Шәхси сайт исеме: http://ildus-amirhanov.ru (блог Ильдуса Амирханова)